МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2023 Казан ш. № п/212

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 5 маендагы п/111 номерлы боерыгы белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 5 маендагы п/111 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 1 ноябрендәге п/294 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең тугызынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4.9 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «п» пунктчасы белән тулыландырырга:

«п) робототехника һәм микроэлектроника өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру кысаларында инновацияле технологик проектлар өчен лаборатория бирү.»;

5.4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) проектның техник һәм корпус компоненты, шулай ук микроэлектроника һәм модельләштерү өстендә эшләү өчен. Лабораториянең 3Д принтерлар, махсус эш өстәлләре һәм зоналары, лазер, фрезер һәм гравировка станогы һәм башка кирәкле җиһазлар белән җиһазландырылган зонасы.»;

13.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.1. Әлеге Кагыйдәләргә кушымта нигезендә бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен Проектларны сайлап алу тәртибе нигезендә сайлап алынган резидентлар өчен бизнес-инкубацияләү хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. Сайлап алудан үтмәгән дәгъвачылар өчен, аларның белдерүләре буенча, бизнес-инкубацияләү хезмәте түләүле нигездә «ИТ-парк» ДАУ боерыгы белән билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә күрсәтелә;

13.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.2. «ИТ-парк» ДАУ, резидентларның гаризалары буенча, «ИТ-парк» ДАУ боерыгында билгеләнгән түләүле хезмәтләрне күрсәтү һәм алар өчен түләү тәртибе һәм шартлары нигезендә бизнес-инкубацияләү хезмәтләре өчен өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтә».

Министр А.Р. Хәйруллин